СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

23 июль, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 80 (8092) | Бәясе билгеләнгәнчә

## Норлат җыен төшерде

Җыен төшерү татар халкының элек - электән килгән матур гадәт - йоласы булган ул. Вакытлар узу белән онытыла башлаган гадәт хәзер бөтенләй яңа бер төсмер - рәвеш алып кабаттан әйләнеп кайтты: берничә ел инде Татарстан мәдәният министрлыгы, татар дәүләт филармониясе һәр җәйдә татар эстрадасының күп кенә танылган йолдызлары, татарлар яши торган төбәкләрдән яшь артистлар катнашында татар яшьләре җыены оештыралар. Норлат әлегә ул җыеннарны ел саен кабул итеп килде. Бу юлы Кол Шәриф мәчете төзелешенә булышлык итү ниятеннән «Иманыбызга кайтыйк» дигән матди ярдәм концерты белән чыккан сәнгать осталары җыенын быел да беренчеләрдән булып Норлат төшерде. Шимбә кичендә шәһәрнең үзәк стадионына җыелган халыкның күплегенә хәйран калырлык иде. Өч сәгатьтән артык җыр, күңелле көйләр яңгырап торды биредә, уен - көлке тынып тормады. Күпсанлы сәнгать осталары, инде танылган артистлар да тамашачыларның күңелен яулау, аларны рәхәтләндереп ял иттерү өчен көчләрен кызганмадылар. Анысы сәнгать осталарына район җитәкчелеге тарафыннан күрсәтелгән игътибар өчен ихтирам билгесе дә булды дип уйларга тулы нигез бар.

- Беренче генә тапкыр килүем булмаса да, норлатлыларның бу юлы тагын да җылырак кабул итүенә һәм халыкның елдагыдан шактый күп килүенә бик күңелебез булып китәбез,- диде Асаф Вәлиев.

- Фатих Сәүбәнович үзе дә сәнгатьне ярата, сәнгать кешеләрен дә хөрмәт итә, халыкның җырга - моңга ихтыяҗы зур булуын да аңлый белә - шулай дип языгыз, - дип өстәде Лидия Әхмәтова.

- Җыен төшерелүнең иң әйбәте сездә,- диде Эльвира Хәйруллина.

Анысына без дә шикләнмибез.

Һәр елны шулай: әүвәл түземсезлек белән басуларның кырдан ачылуын, корыч айгырында җиргә беренче буразна сызар сәгатьләр житүен көтә Анатолий Павлович. Аннан игенчеләргә хас якынлык белән яшь шытымнар борын төртүен, басуларның яшел хәтфәгә төренүен көтә. Шул басуларда җир сөреп, чәчеп, кырларны ашлап, тәрбияләп үстергәнгә һәр башагы, һәр үсентесе кадерле һәм якын шул аңа. Инде кыр өстенә алтынсу сарылык иңә башлагач, ул чабыш аты төсле янә бер тынгысыз ашкыну кичерә. Корыч айгырын куеп, кыр корабы СК - 5не соңгы тапкыр күздән үткәрә, карый - майлый... Ниһаять, ул көн житә - Анатолий Павлович комбайн күперчегенә басып, үзе иңлисе ашлык дингезен карашы белән үтә дә «хәерле сәгатьтә!» дип, шул муллык дулкынына беренче эзне сала... Шуннан соңгы йокысыз төннәр, киеренке хезмәт, тир һәм тузан, ашлык исе шыбырдап әрҗәгә аккан гәрәбә бөртекләр белән түләнеп игенченең гадәти хезмәт биографиясен тәшкил итә. Ай - һай татлы да, бөек тә, катлаулы да ул гадәти язмыш! Моны икмәк белән йөзгә - йөз, күзгә - күз эш иткән кеше үзе генә аңлый, үзе генә белә. Моны, әлбәттә, берничә дистә еллык тәҗрибәсе булган Анатолий



Павлович та, уллары Олег һәм Андрей да яхшы беләләр. Соңгылары җирдән бераз калкуга әтиләре янәшәсендә игенче мәктәбен үтеп үстеләр бит. Хәзер Олег үзе шул ук «Родина» КХАсында механизатор. Әтисе төсле үк тракторда да, комбайнда да бердәй тырышлык белән эшли. Андрей исә ничә ел рәттән әтисендә комбайнчы ярдәмчесе, быел да җаваплы, мәртәбәле эштә ул әтисе янында булачак. Шулай улларының эшчән, тәртипле булып үсүенә куана әти кеше һәм күңеле белән тоя: монда һичшиксез икмәк дигән изге нәрсәнең дә тәрбияви роле зур булган!

Шулай игенче - икмәкне үстерсә, икмәк - үзе үк тәрбияли, үстерә, кеше итә. Анатолий Кольцов язмышын шул игелекле хезмәткә багышлавы белән горур һәм бәхетле.

**Рәсемдә: «Родина» КХАсы игенчесе А.П. Кольцов. Н.КВАШНИНА фотосы.**

## БЕЗНЕҢ АТЛАР - ИҢ ҖИТЕЗЕ

Зур дәрәҗәле күп кенә ярышларда баш килгән атларыбыз, ниһаять, Россиякүләм уздырыла торган иң абруйлы ярышта - Россия Федерациясе Президенты призына үткәрелгән дербида менә дигән нәтиҗәләр күрсәтеп Татарстан һәм шул исәптән районыбызның данын да еракларга таныттылар. Казан сабантуенда Президентыбыз М.Ш.Шәймиев күңеленә иң хуш килгән Ледок кушаматлы һәм район хакимиятенең Альби кушаматлы айгырлары, Пятигорскида узган ул ярышларның финал өлешенә чыгып һәм атаклы башкорт атларын да күпкә кадырып беренчесе шул дәрәҗәле узышта баш килеп Россия Президенты призына лаек булган, икенчесе өченче призлы нәтиҗә күрсәткән.

● *Актуаль темага сорау - җавап*

## АРТЫК ЖЕТОННАРНЫ - ЧЕККА

***Мәгълүм булганча, Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән эшләмәүче пенсионерларны, балалы һәм аз керемле гаиләләрне социаль яклау йөзеннән торак-коммуналь челтәрләр өчен түләүдә кулланылырга тиешле жетоннар әйләнешкә чыгарылды. Күп халык ул жетоннарны тулысынча яки өлешчә урнаштырып килә. Әмма торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә бурычлары булмаган, бигрәк тә үз йортлары белән торучы пенсионерлар ул жетоннарны кая куярга белми аптырыйлар. Безгә дә мөрәҗәгать итүчеләр бар.***

***Һәм без, бу уңайдан, район хакимиятенең халыкны социаль яклау идарәсе башлыгы вазифаларын башкаручы Ф.Ә.Небайкинадан бу мәсьәләдә аңлатма бирүен үтендек.***

Аның язма җавабыннан аңлашылганча, кайбер категория гаиләләрдә тиешле министрлыклар һәм ведомстволар белән килештереп жетоннарның артып калу мөмкинлеген истә тотып, ТР финанс һәм социаль яклау министрлыклары жетоннарны азык - төлек чекларына алмаштыру буенча вакытлы положение эшләгәннәр. Районда бу юнәлештә эш бара да инде. Шуңа күрә, электр уты, газ, фатир өчен түләүләрдә бурычлары булмаган пенсионерларның шәһәрдә яшәүчеләре шул түләүләрне язып бара торган кәгазьләрен алып район социаль тәэминат бүлегенә, ә авыл җирендәгеләр җирле үзидарә Советларына мөрәҗәгать итәргә тиешләр. Аларда эшләүчеләр тикшереп биргән исемлекләр буенча, элемтә бүлекләре жетоннарны азык - төлек чекларына алыштыралар. Бу эшне хат ташучылар башкара. Шунысы бар, алыштырыла торган жетон суммасы пенсия белән бирелгән жетоннар суммасыннан артык була алмый.

## ПЕЧӘН БЕЛӘН СЕНАЖ БЕР ЧАМА

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Әлегә кадәр күп кенә хуҗалыкларда сенаж салуның темп алып китә алмавы турында әйтеп килгән булсак, соңгы көннәрдә бу эш күзгә күренеп кызуланды: соңгы ике - өч көндә уртача меңъярым - ике мең тонна яшел масса базларга салынса, 21 июльдә сенаж запасы дүрт мең тоннадан күбрәккә ишәйде. Шулай итеп кичәге көнгә районда коры печән дә, сенаж да тонналарда тигезләнде. Мичурин исемендәге, «Кондырча»,«Таң», Кузнецов исемендәге, «Чирмешән», «Рассвет» хуҗалыкларында соңгы биш көндә сенаж запасы 600 - 1000 тоннага артты. Берьеллык үләннәрне тулысынча диярлек җыеп алган «Кондырча»да сенаж запасы абсолют саннарда иң күбе - 2700 тонна. «Таң» КХАсында сусыл азык планның 73 проценты кадәр бар инде. Бу эштә бик акрын кыймылдаган «Родина», «Якты Күл» һәм кайбер башка хуҗалыкларда да сенаж базлары тула башлады. Кичәге көнгә бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык берәмлегенең иң күбе Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта - 14 центнер, «Таң»да бу күрсәткеч 11, Мичурин исемендәге, «Рассвет»,«Төрнәс» хуҗалыкларында 10 центнер тирәсе, «Кондырча»да 9 центнердан артыграк. Әмма шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында әллә сенажны кирәксенмиләр, әллә бик яшертен генә эшләп яталар инде - аңламассың. «Игенче», «40 лет Победы», «Алга», «Комбайн»да, МСОның ярдәмче хуҗалыгында сенаж чагыштырмача да, планга карата да әллә ни күп түгел әле. Берьеллык үләннәрне җыеп алып сенажга салу өчен бар мөмкинлекләр дә булган шушы көннәрне ничек тә кулдан ычкындырмаска иде бит. Әлегә алар барлык мәйданның өчтән береннән генә чабылган көе.**

## «Агрофирма» алга карый

***Районның яңа җитәкчелеге ит җитештерүнең дуңгызчылык кебек табышлы тармагын яңадан аякка бастыру максатында күргән нәтиҗәле чараларыннан берсе районда «Татмясопром» холдинг компаниясенең «Норлат» агрофирмасы оештырылуга ирешү булды. Агрофирма, аерым алганда аның составындагы дуңгыз симертү комплексындагы үзгәрешләр турында моннан элек газетада тәфсилләп язган идек инде. Яңа берләшмә бүген дә үзе максат иткән юлдан эзлекле төстә баруында.***

Агрофирма эшчәнлегенең ахыр нәтиҗәсе иң элек ныклы база булуга бәйле икәнлеге мәгълүм. Анысы исә үз чиратында симертүгә куеласы малларның баш санын, ягъни үрчем алуны арттыру һәм шул малларны асрау өчен рәтле абзарлар булдыру кебек ике төп юнәлештән тора. Быел бу юнәлешләрнең икесе дә зур игътибар үзәгендә һәм моның нәтиҗәсе күз алдында. Агрофирма составына кергән «Рассвет» КФХАсы үрнәгендә берләшмәнең башка хуҗалыкларында гына түгел, дуңгыз симертү буенча автомат комплексында да җәйге лагерьлар төзеп дуңгызларны турлап балалату чарасына керешү гаять нәтиҗәле булды. Лагерь шартларында барлыгы өч мең ярым баш дуңгыз баласы алынган, шулай итеп агрофирма составындагы хуҗалыкларда ел уртасына алынган үрчем алты мең баш ярымнан артып киткән. Бу - район буенча алынган барлык яшь үрчемнең дүрттән береннән күбрәген тәшкил итә.

Имүдән аерылган дуңгыз балаларының барысы да автомат - комплексның карантин бүлегенә тупланган. Бүген биредә меңъярым яшь терлек тотыла. Бүген - иртәгә бирегә җәйге үрчемне куячаклар. Ә комплекста симертүгә куелган дуңгызлар саны 5700 башка җиткән һәм бу да узган елның шул чорындагыдан артыграк. Шунысы игътибарга лаек, быел автомат - комплекс эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күзгә күренеп яхшыруга таба.

**( Башы. Ахыры 2 нче биттә).**

# НӨРЛАТТА ҖЫРЛАР ЯҢГЫРЫЙ, ЧУВАШ ҖЫРЛАРЫ



**Кунакчыл Нөрлат җирендә 5 нче ел чуваш халык бәйрәме Уяв үткәрелә. Быел ул иркен шәһәр стадионында уздырылды.**

Кояшлы иртә. Район мәдәният йорты янына Уявка катнашасы фольклор коллективлары җыела. Җылы очрашу, дустанә күрешүдән соң алар колонна булып шәһәр стадионына юл алалар. Милли төсләрдән балкыган колоннаны II нче «Чуваш сандугачы» республика фестивале дипломанты Урта Камышлы авылы мәдәният йортының «Сывлам» («Росинка») фольклор ансамбле (җитәкчесе - ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Н.Бочкарев), Егоркино авыл мәдәният йортының олылар һәм балалар фольклор ансамбльләре (җитәкчесе Ю.Магина) җитәкләделәр. Аннан соң кунаклар - «Чуваш сандугач»ының I - II фестивале лауреатлары - Түбән Камадан «Шанкарав» («Колокольчик») халык фольклор ансамбле (Н.Ефремова), Баулы районының Потапово Тумбарлы авылыннан «Тарават» («Радушие») (М.Максюткин) ансамбльләре атладылар. Уявка Чистайдан «Чистай сандугачлары» чуваш фольклор ансамбле (Л.Долгова), Аксумла, Андреевка авыл мәдәният йортлары фольклор коллективлары (А.Ильин һәм В.Абрамов) килделәр. Парадны бәйрәм хуҗалары, «Чуваш сандугачы»ның I һәм II фестивальләре җиңүчеләре, халык талантларының Бөтенроссия фестивале лауреатлары - «Сялгусь» («Родник») (җитәкчеләре ТРның атказанган мәдәният хезмәткәрләре С.Ефремова һәм Н.Глухов) чуваш җыры халык ансамбле артистлары тәмамладылар.



Бәйрәмдә катнашучыларны милли киемнәрдән кызлар ипи - тоз, ир - атлар милли эчемлек - сыра белән каршыладылар.

Бәйрәмне район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев ачып җибәрде. Сәламлау сүзе белән шулай ук хакимият башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова, Татарстан радиосының чуваш тапшырулары баш редакторы П.М.Миров, Түбән Кама районының чуваш үзәге җитәкчесе, чуваш милли мәдәният автономиясе идарәсе әгъзасы Н.А.Атряскин һ.б. чыктылар.

Ниһаять, ансамбльләр чыгышы башлана, җыр артыннан җыр агыла. Бары җырга чын күңелдән гашыйк затлар гына шулай күңел биреп җырлый, күңел ача алалар. Уяв ахырында Чуваш дәүләт опера һәм балет театры артистларының чыгышы да бәйрәмгә ямьле өстәмә булды.



Бәйрәмдә шулай ук фәнни - этнографик экспедиция дә эшләде. Кунаклар һәммәсе бу чараның югары дәрәҗәдә узуын билгеләп, киләчәктә дә чуваш халкының мәдәни, музыкаль тарихын үстерүдә уңышлар теләделәр.

Мәйданда берочтан спорт - күңел ачу уеннары, халык кул эшләре үрнәкләреннән күргәзмә, «Сыра рәте» эшләде, киосклар, кибетләр сату иттеләр.

Ә кич белән район культура йортында игелек концерты булды. Аннан кергән акча Чулпан авылындагы картлар йортына күчерелде.

**Е.ИЛЮШКИНА.**

**Рәсемдә: бәйрәмнән күренешләр.**

**Н.АЗИЗОВ фотолары.**

# «Агрофирма» алга карый

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә).**

Алты айда симертүдәге дуңгызларның уртача тәүлеклек артымы 482, шул исәптән июньдә 503 грамм чыккан һәм бу күрсәткечләр узган елгыдан 113 һәм 142 граммга артыграк. Ярты елда аннан ит комбинатына гомуми авырлыгы 407 тонна булган 3768 баш дуңгыз китерелеп, бу күрсәткечләр, шулай ук иткә киткән малларның уртача авырлыгы да узган елгыдан шактый югары. Иң мөһиме - малларны тапшыру авырлыгына кадәр симертү срогы уртача ай - ай ярымга кыскарган. Бу комплекста малларны алдынгы технология буенча карау һәм ашату, үз азык цехларын нәтиҗәле эшләтеп, рационны төрле өстәмәләр, шул исәптән Голландиядән кайтарыла торган өстәмәне дә кертеп баету нәтиҗәсе дә булып тора. Шуңа күрә дуңгызчылыкны промышленность нигезендә алып баруның өстенлеге турында бу яктан кистереп әйтергә мөмкин.

Шулай да комплексны аның проект куәтендәге кадәр үк маллар белән тутыру турында сөйләргә иртәрәк әле. Анысы әлегә районда дуңгызчылык белән шөгыльләнүче башка хуҗалыкларда бу эшнең нәтиҗәлелегенә һәм аларның агрофирма белән мөнәсәбәтенә нык бәйле булачак. Әйтик, шул ук карантин бүлеге башка хуҗалыклардан да дуңгыз балалары кабул итәргә әзер. Имүдән аерылган дуңгыз балаларын бирегә күп дигәндә 23 - 25 килограмм авырлыкта китерү мәслихәт - шуннан авыррак булган маллар арзанрак та бәяләнә, аларны комплекстагы үзенчәлекле рационга күнектерү дә авыррак булачак. Районда бу мәсьәләдә комплекс белән тыгыз элемтәдә торучы хуҗалыклар бар. Әмма агрофирма җитәкчелеге моның белән генә тынычланып калырга ярамавын яхшы аңлаган хәлдә дуңгызчылыкны үзләрендә тулы циклда алып баруны тагын да киңәйтүне, ягъни бу мәсьәләдә шактый үк мөстәкыйльлеккә ирешүне максат итеп эшли бүген һәм моның өчен кичектергесез эшлекле чаралар күрү турында кайгырта. Хәзер берләшмә составындагы барлык хуҗалыкларда һәм комплекста терлек каралтыларын яңарту, яңаларын төзү, булганнарын реконструкцияләү буенча киң масштаблы эш бара. Бүгенге көндә барлыгы 13 объектта төзүчеләр мәж килә. Беренче чиратта барлык хуҗалыкларда да ана дуңгызлар абзарлары мал асрарга да уңай булырлык, терлекчеләр хезмәтен дә гадиләштерерлек, ягъни хезмәт чыгымнарын киметерлек иттереп үзгәртеп корыла. Тагын да мөһимрәге, алар барысы да берьюлы асрала торган ана дуңгызларның баш санын кискен арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Башланган барлык төзелеш - реконструкция эшләре үзвакытында төгәлләнгән тәкъдирдә алар берьюлы 1290 баш мал сыйдырырлык булачак. Ә бу исә фирма буенча елына 36 меңгә кадәр дуңгыз баласы алып үстерергә мөмкин булачак дигән сүз. Фирма хуҗалыкларында ел ахырына кадәр тагын 7 меңнән артыграк дуңгыз баласы алу планлаштырыла. Шуңа да бар көч хуҗалыкларда реконструкциягә, ә комплекста яңабаштан төзелә торган дуңгыз абзарларын октябрь ае үрчемен кабул итүгә өлгертүгә юнәлгән.

Агрофирма беренче чиратта дуңгызчылыкны өстенлекле шартларда үстерүне күздә тотса да, хуҗалыкларда терлекчелекнең башка тармаклары, шул исәптән сөтчелек тармагы да кысрыкланмаячак. Киресенчә, мөгезле эре терлек каралтыларының да бик тузганнары яңартылу стадиясендә бүген, ә «Рассвет»та дүрт рәтле абзар сыерларны, тагын ике абзар үстерү группасы малларын бәйләүсез асрау өчен үзгәртеп корыла. Һәр хуҗалыкта, шул исәптән автомат - комплекста да җитештерү биналарын тәртипкә китерү белән беррәттән, эшләүчеләрнең хезмәт урыннарындагы көнкүреш һәм ял шартларын яхшырту буенча да күп чаралар планлаштырылган. Болар һәммәсе яңа берләшмәнең киләчәктә районда дуңгыз ите җитештерү һәм аны эшкәртүдә ( ә агрофирма составындагы ит комбинатында көтелә торган үзгәрешләр турында сүз аерым) бу сүзнең уңай мәгънәсендә монополия тотачагына ышанырга мөмкин булуына нигез булып тора.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

# Айсылу

№1

ХАНЫМНАР, ТУТАШЛАР ӨЧЕН МАХСУС СӘХИФӘ


## КИЛЕШЛЕ ЧӘЧ - ЙӨЗ КҮРКЕ



- Башымны сезгә тапшырам. Ничек килешле-чәчемне шулай кисегез...

- О, менә бу миңа ошый!

Ярлы, төссез чәчтараш бүлмәсендә иҗат башлана.

Чандыр гәүдәле, үткен тере күзле Ирина кулында тарак төгәл йөри, кайчы җитез хәрәкәт итә. Кресло әйләнгән арада көзгегә күз салып аласың: Иринаның йөзендә ниндидер бер рәхәт эшлеклелек хөкем сөрә. Ә үзе тартынмый-яшерми сорауларга җавап бирә.

Ирина Фости - парикмахерскаяда яңа кеше булса да норлатлылар өчен таныш түгел димәс идек. Хатын-кызлар йөзләрендәге күркәмлекне ачарга булышкан килешле прическа ясый белүче останы бик тиз сиземли торган халык бит. Казанда яшәгән Ириның шундый сәләте барлыгын белгәч, кунакка килгән арада да аңа тынгылык бирмиләр. Шулай итеп, үзе Норлатка килгәнче үк даны таралырга өлгерә аның, кушамат та ябышып өлгерә. «Казанская». Телдән-телгә ишетеп тә, ул кискән прическаларны күреп тә аның кулыннан хезмәт күрергә теләүчеләр аны шулай эзләп киләләр. Ишек төбендә аның бушавын озаграк көтәргә туры килсә дә (ә аңа һәрчак чират!), хатын-кыз заты үтә бер үҗәтлек белән аның креслосына утырырга тырыша. Һәм үкенми! Аның каравы, ярлы, төссез чәчтараш бүлмәсеннән башын югары, горур тотып, үз сурәтенә үзе сокланып чыгып китә. (Әйтерсең лә ул чын матурлык салонында булган!)

Ә хатын-кыз өчен чын бәйрәм ләбаса ул!

Шундый кодрәтле куллар иясе үзе турында бизәми-чәчәкләми, кырыс тормыш кыенлыкларын үзенә хас юмор хисе белән сугарып сөйли белә. Югары белемле Ирина (ул Казан икътисад институтын тәмамлаган) яңа һөнәрен башкаланың оста чәчтарашларыннан үзләштергән.

Техник камиллекне алар бирсә, зәвык, матурлыкны тою үз күңеленнән килә, билгеле. Шуңа әле кешеләрне сөйкемле, килешле итеп күрергә теләү омтылышын да өстәсәң, бу бит әлеге һөнәр иясе өчен олы бер хәзинә!

Иринада шул бөтенлек чагыла. Заманча прическалардан «Виктория», «Карэ», «Экспромт» ларны яратып кисә.Эш арасында чәчләрне карау, аларның тере матурлыгын кайтару буенча киңәшләр бирергә дә иренми.

Тагы...

Хәер, Норлатта әле беренче айларын гына эшләп килүче оста турында шушы мәгълүмат җитмәс микән? Кайсыбызның шәхси тормышы, уй-кичерешләре, проблемалары турында язып бетерерлек?Өстәвенә анысы әле Норлат кебек провинциаль шәһәрдә болай да озак сер булып тормый...Иң мөһиме, чәчтарашыбызда Ирина атлы яңа оста эшли башлады.Үз йөзегезнең күркәмлеген күрергә, килешле башыгызда көнләшү-кызыгулы карашлар тоярга теләсәгез, сезгә нәкъ менә ул булыша алыр дип уйлыйбыз.

**С.Нуруллина.**



С.МАЙСТЕР фотосы.

*Чибәр дә син,*
*Сылу да син,*
*Тик сагыш күзләреңдә.*
*Нинди уйлар күләгәсе*
*Шом салган йөзләреңә?*
*Керфекләреңнең очыннан*
*Яшь менә тамар кебек.*
*Кем киптерер ул яшьләрне*
*Күзкәйләреңнән үбеп?*
*Син якты сагышың аша*
*Елмай әле дөньяга.*
*Түземле затларга гына*
*Язмыш елмаеп бага.*

## ГОМЕРГӘ ЯШЬ БУЛЫП

*КИҢӘШЛӘР*

Һәркемнең гомергә яшь булып каласы килә. Моңа ничек ирешергә? Тибетта табылган рецепт моны уңай хәл итәргә мөмкинлек бирә. Менә ул рецепт:

100әр грамм коры ромашка, сары мәтрүшкә, үлмәс гөл (бессмертник), каен бөресе алып катнаштыралар. Бер аш кашыгы катнашманы ике стакан ярым кайнар суга салып, томалап 20 минут чамасы төнәтәләр. Аннары сөзеп, түбен сыгып алалар. Төнәтмәнең бер стаканын бер бал кашыгы бал эретеп кичке аштан соң эчәләр. Иртәнгә кадәр башка нәрсә ашарга да, эчәргә дә ярамый.

Икенче иртәдә сыеклыкның калганын 50 - 60 градуска кадәр җылыталар, бер балкашык бал салалар һәм ач карынга эчеп җибәрәләр. 20 минуттан соң иртәнге ашны ашарга ярый. Коры катнашма беткәнче көн саен шулай эшлиләр.

Матдәләр алмашын яхшырту һәм организмны чистарту өчен бу эшне 2 - 3 ел саен кабатлыйлар.

## Инициаллар нәрсә турында сөйли?

Кеше холкын билгеләүнең төрле ысуллары бар. Күп кенә тәҗрибәләрдән күренгәнчә, инициаллар да кемнең - кемлеген абайларга ярдәм итә икән. Әйдәгез, бергәләп тикшереп карыйк.

***А*** - көч һәм хакимлек
***Б*** - олы хисләргә сәләтлелек
***В*** - аумакайлылык, эзлексезлек
***Г*** - серлелек
***Д*** - аралашучан, кешеләрне үзенә тартып торучан
***Е*** - хәзерлекле, сабыр
***Ж*** - үз көченә ышанып бетмәү
***З*** - канәгатьсезлек, шикләнүчәнлек, матди кыенлыклар
***И*** - тәэсирләнүчән, даими киеренкелек
***К*** - таләпчәнлек һәм тынгысызлык
***Л*** - вакчыллык, логика, тапкырлык
***М*** - хезмәт сөючәнлек һәм үтә вакчыллык
***Н*** - дәртлелек һәм иҗади тәкәбберлек
***О*** - хислелек, тынгысызлык
***П*** - тыйнаклык һәм ялгызлыкка омтылу
***Р*** - даими киеренкелек, көчле хис
***С*** - төшенкелеккә бирелүчән, тиз кызучан
***Т*** - туктаусыз эзләнү, идеал артыннан куу
***У*** - кәефсезлек, сизгерлек, курку
***Ф*** - ягымлылык, яраклашу
***Х*** - җенси проблема, хисләрнең үзгәрүчәнлеге
***Ц*** - эчке кичерешләрне тышка чыгаручан
***Ч*** - тугрылылык
***Ш*** - көнчел, юл куймаучан
***Щ*** - үчлелек, интеллектуаль сәләт
***Э*** - рухи тотнаклыкка омтылучан
***Ю*** - икейөзлелек, тәкәбберлек
***Я*** - зыялылык, иҗади сәләт

## Әрекмән дә бүләккә бара



Дәртле **кучкар**, кызыл мәк һәм лаләләргә шатланыр. Романтик күңелле кучкарлар күңеленә нәфис фиалкалар, анемоннар, ипомея, хуш исле борчак хуш килер. Инде кучкарның тискәреп беткән үзсүзлесенә тотыгыз да әрекмән бүләк итегез!

***



**Үгезбозау** маргариткалар букетын ярата.Аларның нәфис, гашыйк җанын сирень һәм ландыш чәчәкләре дә эретер. Кул астында аларның берсе дә юкмыни? Ул чакта тузганак бүләк итегез!

***



**Игезәкләргә** нәркәсләр бирегез. Аларга гади лютиклар да, гүзәл розалар букеты да бер үк дәрәҗәдә кадерле булачак.

***



Эмоциональ һәм сизгер **кыслаларга** ак, нәфис чәчәкләр туры килә: ясмин,жилгалость,дельфиншум.

***



**Арыслан** һәм **чаянга** хризантеналар ошый.

Рәсми ситуацияләрдә **Арысланнарга** озын кашкарыйлар, ә дустыгызга миндаль ботагына лаванда куярга мөмкин.

***



Астра-**Кыз** талисманы. Алар гади үги ана яфрагына да, кызыл шалфейга да шатланалар.

***

**Бизмәнгә** Анютины глазки бик туры килә.

***



**Укчы** талисманы итеп зәңгәр чәчәкне сайлар.

***



**Сукояр** зәңгәр гиацинтны ошата , ә **Кәҗәмөгез**-кыңгырау чәчәкне. Фиалка, умырзаялар шулай ук аның яраткан чәчәкләре.

**(«Женщина» газетасыннан).**

## Кемгә нинди төс кирәк?

***Сәламәтлегегезгә уңай тәэсиритүче төсләрне исегездә тотыгыз.***

***Кучкар. (21 март-20 апрель)*** -куе алсу,кызыл, алтынсу сары, шулай ук барлык ялтыравык төсләр.

***Үгезбозау (21 апрель-20 май)*** - бөтен язгы төсләр: ачык сары,ак,яшел һәм аксыл шәмәхә.

***Игезәкләр (21 май-20 июнь)***- кызгылт сары, аксыл сары, күксел,зәңгәр һәм шәмәхә.

***Кысла (21 июнь-22 июль)***- аксыл шәмәхә, көмешсу, яшел борчак төсе, аксылрак әфлисун төсе.

***Арыслан (23 июль-22август)***- ал, саргылт көрән,куе кызыл, диңгез төсе.

***Кыз ( 23 август-23 сентябрь)***- ак, аксыл,зәңгәр,яшел.

***Бизмән ( 24 сентябрь-23 октябрь)***- кара зәңгәр, куе кызыл,диңгез төсе.

***Чаян ( 24 октябрь-21 ноябрь)***- ачык кызыл, ал, барлык ут төсләре.

***Укчы (22ноябрь-21 декабрь)***- зәңгәр,яшел, шәмәхә, куе кызыл.

***Кәҗәмөгез ( 22 декабрь-19 гыйнвар)***- кара, карасу көрән, көлсу төс, зәңгәр, аксыл сары.

***Сукояр ( 20 гыйнвар-18 февраль)***- янкелт,зәңгәр,ачык зәңгәр, шәмәхә.

## Бакча - йорт Бакча - йорт

# Баллы булыйк дисәгез

Кортлар өчен төп табыш гадәттә июльнең беренче яртысында юкә, карлыган кебек агачлар мул баллы чәчәккә төренгән, алар артыннан карабодай чәчәк аткан чорда башлана. Төп табыш чоры юкәдә ике атна, карабодайда һәм болын чәчәкләрендә өч атна дәвам итә. Бу чорга корт гаиләләрен әзерләү тәгәлләнә: көч аеру мөмкинлеге бетерелә, картайган һәм ана кортлар алыштырыла, оялар киңәйтелә.

Ләкин шундый хәлләр дә була: июньдә һава бозылып китә дә умарталарны баллы үсемлекләр тирәсенә, урманга күчереп урнаштырырга комачаулый. Андый чакта бу эшләр июльгә кала. Умарталарны урман кырыена куаклар күләгәсенә куялар. Шулай эшләгәндә кортларга ояларын җилләтеп суыту өчен көчләрен сарыф итәргә туры килмәс. Моңа да карамастан, табыш чорында күп кенә кортлар оя җилләтү белән шөгыльләнсәләр, кояш баегач «сакал» булып җыелып торсалар, умарта эчендә бөркү дигән сүз. Кортларга тиз арада булышу, умарта оясын җилләтү чарасын күрү сорала. Моның өчен умартаның корпусын яки магазинын 5-8 см га күтәреп куялар. Шулай эшләгәндә, ояның җилләнүе яхшыра, бөркүлек кими.

Кортларның продуктлылыгын күтәрүдә, умарталарның әйбәт җилләтелүе белән бергә, табышны кую урыннары булу да һәм тиз арада һәм тоткарлыксыз үз умарталарын таба алулары да бик әһәмиятле. Бу максаттан чыгып, умарталарны төрле ориентларга бәйле рәвештә урнаштыралар, аскы тишемнәр янына очып төшү такталары куялар. Кортлар очып киткәндә һәм кайтып кергәндә комачауламасын өчен үләннәрне чабып торалар. Чөнки бүксәләрен тутырып баллык алып кайтучы кортлар кечкенә генә үләнгә бәрелсәләр дә, җиргә егылып төшәләр, үлән арасыннан чыгу өчен кадерле вакытны әрәм итәләр, бу исә ахыр чиктә аларның бал ташуына тискәре йогынты ясый.

Умартачылар төп табыш вакытында эшче кортлар кәрәз ясау белән шөгыльләнеп көчләрен сарыф итүгә юл куймау, кортларга баллык салу өчен һәрвакыт буш оя булдыру турында кайгырталар.

Барлык кәрәз оялары да бал белән тутырылгач, бал алырга керешергә була. Бер корпуслы умарталарның яки магазиннарның баллы рамнарын 5-8 көннән алалар. Иң яхшылап ябып куелган күзәнәкле рамнарны кышка кортлар тукландыру өчен калдыралар. Гадәттә аларны махсус урыннарда саклыйлар һәм умарта ояларын кышка әзерләгәндә көздән, ә кайбер вакытта, кортларга ашату өчен бал җитмәвен сизгәндә, кышын да куялар.

Аертырга алынган рамнарны ясалма кәрәз куелган буш рамнар яки ярымрамнар белән алыштыралар.

Ике катлы, күп корпуслы һәм тумыран умарталардан балны төп табыш чоры узгач кына алалар. Чөнки аларда бал җыю өчен урын һәрчак җитәрлек була һәм аны теләгән вакытта арттырырга мөмкин.

Кортларны эшләгән вакытларында борчымас өчен, балны кич белән суырталар. Балны суыртып алу белән, бушаган рамнарны һәм ярымрамнарны шунда ук умартага куялар. Балны дюралюмин бидоннарга һәм фләгаларга яки сөян тәпәннәргә агызалар. Саксыз караш нәтиҗәсендә бал бозылырга да, кырмыска, шөпшә, бал кортлары һәм башка бөҗәкләр тарафыннан урланырга да мөмкин.

Күп кенә һәвәскәр умартачылар көч аерту, карт ана кортларны яшьләре белән алыштыру кебек эшләрне яз-

### Умартачыга киңәшләр



дан эшләмичә, төп табыштан соңга июль ахырына-август башларына калдыралар. Бу язгы һәм июнь аендагы кыйммәтле табыш вакытын әрәм итмәү өчен шулай эшләнә.

Эшче кортларның ана сөте эшләп чыгаруын арттыру өчен аерырга билгеләнгән семьяга башта бал икмәге ашатам. Оя уртасына аксыл-коңгырт кәрәзле бер-ике рам куям. Ике-өч көннән соң, ул кәрәзләрдә личинкалар барлыкка килгәч, оядан ана кортны алам. Бал кортлары бу кәрәзләрдә ятимлек сизәләр һәм ана кортка оя ясыйлар. Шулар төзелеп беткәч, мин аларны яңа оешкан аерыларга бирәм.

Июль азагында, ана корт оялары әзер булгач, 12 рамлы семьяны ике өлешкә, ә 18-20 рамлысын өчкә бүләм, шуларның һәркайсына әзер ана корт оясы куям. Мондый һәр семьядан ике-өч аеры барлыкка килә. 15-20 көннән соң яшь аналар бу аерылар белән тирәләп очалар һәм күкәй сала башлыйлар, ә карт кортлар балаларны тырышып тәрбияли, кыр-болыннарда табыш эзли, кәрәзләр төзи, кызу эш бара.




### Помидор + тузганак = мәхәббәт

Канада бакчачылары помидорны тузганак белән аралаштырып утырталар. Моның хикмәте бар. Тузганактан чыга торган цикор кислотасы җирдәге тимергә тәэсир ясый һәм фузариум дигән туфрак гөмбәчеген кирәкле матдәләрдән мәхрүм итә.

### Бөҗәкләр химия белән дус түгел

Химик препаратларны черки, озынборыннар яратмый. Бу препаратларны репеллент диләр. Алар крем («ДРЭТА», «Ультратон», «Табу - Б»), лосьон («Эвител», «Даст - 2», «Дефизоль», «Аутон») итеп чыгарыла. Аларны тәннең ачык урыннарына сөртәләр.

Бөтнек исен, бөтнек тамчыларын элек - электән черки куркыту өчен кулланганнар. Бөтнек тамчыларын тәнгә сөртәләр. Лаванда (ала миләүшә) мае да ярый. Кәнәфер исе килгән духи, одеколоннар да кулланырга була.

### Фитофтороз нидән була

Фитофтороз - еш очрый торган помидор авыруы. Ул һавада 15 - 21 градус температура торганда килеп чыга һәм бакчачыны бөтенләй уңышсыз калдырырга мөмкин. Фитофтороз һава дымлы вакытта, чык мул төшкәндә, томанлы көннәрдә, төнге һәм көндезге температураның кискен алышынуы, үсентеләрнең артык куе һәм чүпле булуыннан һәм помидорның бәрәңге белән янәшә утыртылуыннан килеп чыга.

# Черкидән котылыйк!

***Җәй көне дөнья матур, рәхәт, әмма... черки, озынборын интектерә. Ничек ул канэчкечләрдән котылырга?***

**Р.ГАЛИЕВА.**

Беренче чиратта тәрәзә төпләренә озынборыннар өнәми торган үсемлекләр, гөлләр куярга кирәк. Мәсәлән, пеларгония, мирт, розмарин гөлләрен. Кичен гөлләрне селкетеп алсагыз, исе бөтен бүлмәләргә таралыр. Тәрәзә төбенә помидор сабаклары, кара дүләнә яфраклары яки бөтнек, песи борчагы, дару үләне булган мелисса кую да файда бирә.

Кечкенә тәлинкәгә скипидар салып, ишек, тәрәзәләрне ябып фатирдан чыгып торыгыз. Берничә минуттан черки, озынборыннар идәнгә егылып төшәр, себереп аласы гына кала.

Исле тәтенне дә бу бөҗәкләр яратмый. Бәбрия (розмарин), кара дүләнә, ала миләүшә (лаванда) ботакларын көйдереп алыгыз.

100 грамм камфараны газ горелкасы өстендә тотып, исен чыгарсаң, зур мәйданнарны да бөҗәкләрдән арындырып була.

## Белдерүләр



### Сатабыз

**1987 елгы ВАЗ - 21063**. Тел.: 2 - 23 - 76.

***

**Шәһәр үзәгендә 2 бүлмәле фатир**. Тел.: 2 - 14 - 55.

***

**Ак төстәге яңа ГАЗ - 3110, 76лы бензинда эшли, 5 баскычлы тартма, чайка күперчеге, велюр салон, бәясе - заводныкыннан арзан**. Тел.: 65 - 3 - 11.

***

**1991 елгы «Москвич - 2715 - 01».** Иске Максимкинода Оренбуровларга мөрәҗәгать итәргә.

***

**Зне бозаулаган сыер**. Тел.: 2 - 11 - 31.

***

**Суворов урамында 99нчы йорт.** Тел.: 2 - 27 - 49.

***

**1984 елгы ВАЗ - 2106.** Адрес: Советская ур., 187 - 26.

***

**1997 елгы ВАЗ - 91065, 1996 елгы ВАЗ - 21093, бәясе заводныкыннан түбән**. Адрес: Гыйматдинов ур., 9. Тел., 2 - 20 - 79.

***

**1993 елгы, әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21063.** Тел.: 5 - 28 - 07, 17 сәг.,тән соң.

***

**ГАЗ - 24 һәм 5 х 3,5 метрлы бура.** Адрес: Южная ур., 42.

***

**Кормыш микрорайонында аз гаиләлеләр йортында 1 бүлмәле фатир һәм чистарту корылмалары районында гараж**. Адрес: Пионерская ур., 36.

### Төрлесеннән

**Циолковский урамында ике бүлмәле фатир Кормыш микрорайонында яки үзәктә шундый укка алыштырыла. Вариантлар мөмкин.** Тел.: 5 - 12 - 35 (17 сәг.тән соң).

***

**Фәтхетдинов Ф.Ф.исеменә бирелгән машина йөртү таныклыгы һәм машина документлары табучыны Тельман ур., 6 - 24 адресы буенча бүләк бәрабәренә иясенә кайтарып бирүләрен сорыйбыз**. Тел.: 2 - 28 - 94.

***

**1 нче мәктәп тарафыннан Захаров Александр Николаевич исеменә бирелгән 845161 номерлы аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

**Мусаев Сергей Анатольевич исеменә машина йөртү таныклыгы һәм техпаспорт табучыны бүләк бәрабәренә Тукай ур., 54 адресы буенча иясенә кайтарып бирүләрен сорыйбыз.**


***Идел Буе региональ наркология үзәге***

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, 1, 15 августта көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.


6 номерлы «Кояшкай» мәктәп - балалар бакчасы коллективы улы Тәлгатьнең фаҗигале төстә вафат булуы сәбәпле, пешекче Гамбәрия Фатыйх кызы Әхмәтшинаның тирән кайгысын уртаклаша.

2 нче мәктәпнең 7 «А» класс укучылары һәм класс җитәкчесе уллары Тәлгатьнең фаҗигале төстә вафат булуы сәбәпле, Әхмәтшиннар гаиләсенең авыр хәсрәтен уртаклаша.

«Норлатнефть» УТТсы администрациясе, профсоюз комитеты әниләренең вакытсыз үлүе сәбәпле, шәфкать туташы Ирина Ильинична һәм I автоколонна шоферы Илгиз Шакирович Шәйхиевларның авыр хәсрәтен уртаклаша.

«Норлатнефть» УТТ сы администрациясе, профсоюз комитеты иренең вакытсыз үлеме сәбәпле, диспетчер Мортазина Зөлфия Шәрифҗанованың тирән кайгысын уртаклаша.

«Норлатнефть» УТТсы администрациясе, профсоюз комитеты әтисе үлү сәбәпле, 4 колонна шоферы Дәүләтшин Газинур Рөстәм улының тирән хәсрәтен уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә.